Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең
«48 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»
муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе

# «Мин татарча сөйләшәм! » акциясе




Куратор: 1.Султаншина М.И.

2020-2021 нче уку елы

- 48 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе
- “Мин татарча сөйләшәм!” акциясендә актив катнаштылар. Бу акциянең төп максатлары – татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, дәүләт телен өйрәнүгә ихтыяж тәрбияләү.
  “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе узган көннәрдә безнең мәктәп укучылары китапханәгә, кибеткә, даруханәгә, шифаханәгә, шәһәр паркына экскурсияләр оештырдылар. Мәктәп укучыларыбыз шулай ук интернетта бер-берсе белән татарча аралашырга тырышалар.
- “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе милләтебезгә һәм телебезгә карата ихтирам уята.
- Бу акциядә барлыгы 150 кеше катнашты.

“Минем татарча беренче 150 сүзем” исемле буклет төзедек һәм аны таратуны мәктәбебездән башладык. Фән укытучыларына, мәктәп админстрациясенә, аш пешерүчегә, китапханәчегә, техник хезмәткәрләргә бүләк иттек.











## Мои первые 150 слов на татарском языке

- и - Мама
- и - Папа
- и - Бабушка
- бай - Дедушка
- и - Тетя, Сестра.
- ий - Дядя, Брат.
- ам - Привет.
- бул - Пока.
- мәт - Спасибо.
- - Дом.
- и-Хлеб
- ктәп-Школа
- фтәр-тетрадь
- ста-доска
- бур-мел
- әл-стол
- индык-Стул
- ндәлек-дневник
- ом-пол
- ләм-потолок
- ләм-ручка
- әзә-окно
- ек-Дверь
- рес-урок
- учы-ученик
- итап-книга
- ытучы-учитель
- ергеч-Ластик
- нмесез-здравствуйте!

**Положение**

**о республиканском конкурсе-акции**

**«Мин татарча сөйләшәм!» («Я говорю по–татарски!»)**

В целях реализации государственной программы Республики Татарстан «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014-2020 годы», в соответствии с планом работы Министерства образования и науки Республики Татарстан на 2014/15 учебный год проводится республиканский

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең
«48 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»
муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе



"Мин татарча сөйләшәм"

мин татарча сөйләшәм!

"Я говорю по-татарски"

# Буклетны барысы да бик шатланып кабул иттеләр.






Безнең яраткан укытучыларыбыз да бу чарадан читтә калмыйлар.

“Мәдәният һәм сәнгать дөньясы” дип исемләнгән конкурс - викторинада 9нчы сыйныф укучылары үзләренең татар мәдәнияты һәм сәнгате өлкәсендә белемнәрен күрсәтеп 2 дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнделәр.



“Әкиятләр иленә сәяхәт” конкурсында 2 б сыйныфы укучысы
Ризатдинова Амира
“Аю белән бабай“ татар халык әкиятен сәхнәләштерде.





Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе
Муниципаль автономияле
өстәмә белем бирү оешмасы
«15 нче санлы Балалар иҗат йорты»

Диплом

«Әкиятләр иленә сәяхәт»
бәйгесе
«Мин татарча сөйләшәм!»
шәһәр программасы
2 этап

**№ 48 нче мәктәп командасы**
(җитәкчесе: Шарапова Р.М.)

«№ 15 нче Балалар иҗат йорты»
директоры С.Н. Грачева


14-19 октябрь 2020 ел



Бөек Ватан сугышы елларында республикабызның тарихына, мәдәниятына багышланган «Туган ягым тарихы» дип исемләнгән бәйгедә катнашып 6нчы сыйныф укучылары 3 дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр.



Татар теле укытучылары Туган тел елына багышланган  кичә үткәрделәр. Кичәдә укчылар шигырьләр сөйләделәр, җырладылар









**“Шигъри гөлләмә”нәфис сүз остасы бәйгесендә 2нче, 9нчы сыйныф укучылары I нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр.**

**Ризатдинова Амира(2б)**

**Ф.Сафин «Киләчәктә»**



**Мифтахова Лилия (9Б)**

**К.Сибгатуллин «Шәһәрләрдә татар теле укытучылары»**



Рус балаларына татар телен уңышлы өйрәтү өчен алшартларның берсе- алар белән татар телендә төрле кичәләр оештыру, сыйныфтан тыш чаралар үткәрү. Әлеге дәрестән тыш эшләр белем һәм тәрбия бирүдә бердәм процесс буларак дәресләрнең дәвамы итеп бәяләнә. Шуны истә тотып, 3 нче ел инде “Мин татарча сөйләшәм” акциясендә катнашабыз. Чараларны план нигезендә үткәрәбез.



“Мин татарча сөйләшәм” республикакүләм акция кысаларында узучы «Уйнап, җырлап күңел ачыйк» номинациясендә “Татар халык уеннары” конкурсында катнашып 7 сыйныф укучылары 3 нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр. Бәйгедә кызлар, егетләр татар халкының “Түбәтәй” милли уены белән таныштырдылар.






# Туган тел елына багышланган шәһәркүләм гәҗит бәйгесендә катнаштык.










96 сыйныф укучылары туган тел елына багышлап стенд төзеделәр.

# шифаханәдә

- Лилия Газизовна, “Мин татарча сөйләшәм”акциясе кысаларында сезгә берничә сорау бирергә рөхсәт итегез:

- Туган телегез дип кайсы телне санайсыз?

- Туган телем дип мин татар телен саныйм.

- Туган телегезне сез яратасызмы?
- Әйе, әнкәм телем мин бик яратам һәм хөрмәт итәм.

- Туганнарыгыз, дусларыгыз белән нинди телдә аралашасыз?

- Өлкәнрәк яшьтәге кешеләр белән татар телендә аралашам, ә авыручылар белән күбрәк русча сөйләшергә туры килә.

- Сез үзегезне “татар телен яхшы беләм” дип саныйсызмы?

- Мин үземне татарча яхшы белүчеләр санына кертәм.

Әңгәмәне оештырды: яшь журналистлар

4 нче Б сыйныфы укучылары .



# Даруханәдә кунакта









Надежда Михайловна 2 ел рәттән бу чарага бик теләп катнаша. Бу юлы инде ул безне “Исәнмесез”, “Рәхим итегез” диеп каршы алды.

# Хастаханәдә кунакта






# Хастаханәдә ел саен безне бик җылы каршы алалар.







# Шәһәр паркында

"Мин  татарча сөйләшәм" акциясендә узган ел 20 кеше катнашса, ә быел катнашучылар саны артты.








# Китапханәдә

- \- Исәнмесез!
- \- Исәнмесез, балалар! Сезгә нинди китаплар кирәк?
- \- Миңа Николай носовның “Белмәмеш һәм аның дуслары мажаралары” кирәк.
- \- Ә сиңа?
- \- Миңа Муса Җәлилнең “Кызыл ромашка” шигыре кирәк.
- \- Рәхим итегез!
- \- Рәхмәт! Ә сезгә минем сеңелемә язылырга мөмкинме?
- \- Ә аңа ничә яшь?
- \- Ун яшь. Ул минем белән бер мәктәптә укый.
- \- Мөмкин. Икенче вакыт бергә килегез.
- \- Рәхмәт, сау булыгыз!






# Яр Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр челтәренең 22 нче филиалында











# Ак Барс банычгына сәяхәт






# Ашамлыклар кибетендә

- - Исәнмесез!
- - Исәнмесез!
- - Сездә “Левушка” конфеты бармы?
- - Әйе, бар. Күпме үлчәргә?
- - Ә килосы ничә сум тора?
- - Йөз кырык сум.
- - Ярты кило үлчәгез әле.
- - Рәхим итегез. Тагын нәрсә аласыз?
- - Бер литр сөт һәм бер ак ипи.
- - Сездән йөз унҗиде сум акча.
- - Нишләп алай күп?
- - Җитмеш сум конфет, утыз ике сум сөт, унбиш сум ипи, санап карагыз!
- - Гафу итегез, мин сөтне егерме сигез сумнан санадым.
- - Зыян юк, сөтнең бәясе күтәрелде бит.
- - Ярар, сау булыгыз!



# Ашханәдә кунакта



Вера Николаевна тәмле үлән чәе белән сыйлый

Мәктәптәге ашханәне
Барыбыз да ярата.
Чөнки мондагы апалар
Безне тәмле ашата.
Ягымлы алар үзләре,
Йөзләре көлеп тора.
Апалары әйбәт булгач,
Ашыйсы килеп тора.



# Милли ризыклар пешерү конкурсы





# Әкияттә кунакта







“Оста шигырь сөйләүче” конкурсы үткәрелде. Конкурста барлыгы 15 шигырь сөйләүче катнашты.



Бурмистрова Юлия 2 сыйныф -1 урын
М.Җәлил. “Карак песи”



Асмакаева Вероника -2 урын
Э.Мөэминова “Туган ил”

# Балалар бакчасында кунакта



Татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә оештырылган һәр чара мәктәптә оешкан төстә, кызыклы итеп уздырылды. Чараларда барлык мәктәп укучылары да актив катнаштылар. Бик актив укучылар мактау грамоталары, дипломнар белән бүләкләнделәр.



«48 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»
муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Султаншина Миләүшә Исрафил кызы.

